ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл жирлеге Советы

422756, ТР Әтнә муниципаль районы,
Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8
тел. 34-6-25

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Большеменгерского сельского поселения
Атнинского муниципального района

422756, РТ, Атнинский муниципальный район,
село Большой Менгер, улица Советская, 8
тел. 34-6-25

**КАРАР**

27 ноябрь 2024 ел № 104

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 2 июлендәге 73 номерлы карары белән расланган Олы Мәңгәр авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Автомобиль юллары һәм Татарстан Республикасы территориясендә юл эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасы Законының 11 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында” 2024 елның 17 октябрендәге 84-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм "Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында" Татарстан Республикасы Законы, Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Уставына таянып, Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 2 июлендәге 73 номерлы карары белән расланган Олы Мәңгәр авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.2 пунктының 6 пунктчасындагы ", җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан машина кую урыннарын (машина кую урыннарын) түләүле нигездә файдаланган өчен" дигән сүзләрен гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карар 2025 нче елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында: http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ф.Филатова